**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ЗАКУПКАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**12.04.2016** № **04-14-49**

Казан ш.

Татарстан Республикасының сатып алулар буенча Дәүләт комитетында норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында

2009 елның 17 июлендәге «Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» 172-ФЗ Федераль законга, Россия Фкдкрациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге «Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» 96нчы Карарына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 декабрендәге 883нче карарына ярашлы рәвештә боерык бирәм:

1.Татарстан Республикасының сатып алулар буенча Дәүләт комитетында беркетелгән норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы Тәртибен расларга.

2.Татарстан Республикасының сатып алулар буенча Дәүләт комитетында норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасын уздыру өчен җаваплы вазифадагы зат итеп үзәкләштерелгән сатып алулар бүлеге җитәкчесе урынбасары А.А.Фәтхетдиновны билгеләргә.

3.Коррупциягә каршы экспертизага килгән норматив хокукый актлар һәм норматив хокукый актлар проектлары исәбе Кенәгәсен алып баруда җаваплы зат итеп сатып алуларны методологик алып бару бүлегенең әйдәп баручы консультанты И.Г.Шәриповны билгеләргә.

4.Әлеге боерыкның үтәлешен контрольгә алуны үземдә калдырам.

Рәис О.А. Редько

Татарстан Республикасының
сатып алулар буенча
Дәүләт Комитеты
_________________елның_____санлы
боерыгы белән расланган

**Татарстан Республикасының сатып алулар буенча Дәүләт комитетында норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасын уздыру**
**Тәртибе**

**1.Гомуми положениеләр**

1.1.Әлеге Тәртип Татарстан Республикасының сатып алулар буенча Дәүләт комитетында (алда - Дәүләт комитеты) норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының (алда – актлар, актлар проектлары) коррупциягә каршы экспертизасын уздыру процедурасын билгели.

1.2.Коррупциягә каршы экспертиза «Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ Федераль законга ярашлы рәвештә Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган норматив хокукый актлар һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасын уздыру методикасы буенча уздырыла (алда – методика).

1.3.Коррупциягә каршы экспертизага килгән актлар (актлар проектлары) коррупциягә каршы экспертизага килгән норматив хокукый актлар һәм норматив хокукый актлар проектлары исәбе Кенәгәсендә теркәлә (алда – Кенәгә) (әлеге Тәртипкә 1нче Кушымта).

1.4.Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча әлеге Тәртипнең 2нче Кушымтасына ярашлы рәвештә форма буенча йомгак ясала һәм анда түбәндәге белешмәләр бирелә:

экспертизага бирелгән актлар реквизитлары (акт проекты исеме);

экспертиза уздыру өчен нигезләмә;

актта (акт проектында) коррупциоген факторлар булу-булмау;

коррупциоген факторлар булган актларның конкрет положениеләре (акт проектында);

хокукый нормаларны үзгәртү яисә коррупциогенлыкны бетерү өчен аерым нормаларны алып ташлау буенча тәкъдимнәр.

## 2.Дәүләт комитеты актларының коррупциягә каршы экспертизасы

2.1.Дәүләт комитеты актларына коррупциягә каршы экспертиза үзәкләштерелгән сатып алулар бүлеге җитәкчесе урынбасары яисә аның вазифасын башкаручы бүлек хезмәткәре тарафыннан үткәрелә (алда – җаваплы зат).

2.2.Дәүләт комитеты актларына коррупциягә каршы экспертиза структур бүлекчә инициативасы буенча чыгарылган актка мониторинг уздырганда коррупциоген факторлар ачыкланганда һәм шулай ук актларда коррупциоген факторлар булуы турында мәгълүмат алынганда җаваплы зат тарафыннан үткәрелә. Актларны шулай ук экспертиза уэдыру өчен Дәүләт комитеты җитәклеге җибәрергә мөмкин.

Коррупциягә каршы экспертиза көчен югалткан яисә юкка чыгарылган норматив хокукый актларга ясалмый.

2.3. Актлар коррупциоген фактор ачыкланган көнне ярашлы мәгълүмат алганнан яисә Дәүләт комитеты җитәкчелеге акт җибәргәч Кенәгә алып баруга җаваплы зат тарафыннан теркәлә. Кенәгә алып баруга җаваплы зат Кенәгәдә теркәлгән көннән алып бер эш көне эчендә Дәүләт комитеты актын экспертиза уздыру өчен җаваплы затка тапшыра.

2.4.Коррупциягә каршы экспертиза актның Кенәгәдә теркәлгән көненнән алып ун көн эчендә үткәрелә.

Актның коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәсе әлеге Тәртипнең 1.4нче пунктына ярашлы рәвештә җаваплы зат төзегән нәтиҗә нигезендә ясала һәм Кенәгәдә күрсәтелә.

2.5.Нәтиҗә җаваплы зат төзегән һәм кул куйган көннән алып бер эш көненнән соңга калмыйча Дәүләт комитетының үзәкләштерелгән сатып алулар бүлеге эшен оештыручы рәис урынбасарына, яисә аның вазифасын башкаручыга җибәрелә. Рәис урынбасары (аның вазифасын башкаручы) нәтиҗәгә виза сала һәм рәискә яисә аның вазифасын башкаручыга тапшыра.

2.6.Рәис актта коррупциоген факторлар барлыгы турында йомгак нәтиҗәсе буенча аңа үзгәрешләр кертү кирәклеге яисә аның үз көчен югалтуы турында карар кабул итә.

2.7.Структур бүлекчә инициативасы белән чыгарылган акт Дәүләт комитеты рәисенең әлеге Тәртипнең 2.6нчы пунктында күрсәтелгән карарын кабул иткән көннән алып өч көн эчендә Дәүләт комитетының ярашлы проектын әзерли һәм аны коррупциягә каршы экспертиза өчен җаваплы затка җибәрә. Андый проектның

коррупциягә каршы экспертизасы әлеге Тәртипнең 3нче кисәгенә ярашлы рәвештә үткәрелә.

## 3. Дәүләт комитеты актлары проектларының коррупциягә каршы экспертизасы

3.1.Дәүләт комитеты актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза берүк вакытта аларның хокукый экспертизасын ясап үткәрелә.

Дәүләт комитеты актлары проектлары әлеге проектларны эшләү өчен җаваплы Дәүләт комитеты структур бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан (алда- җаваплы зат) үзәкләштерелгән сатып алулар бүлеге җитәкчесе урынбасарына җибәрелә.

3.2.Дәүләт комитеты актлары проектлары (алда – проектлар) килгән көнне Кенәгәдә Кенәгә алып баручы тарафыннан теркәлә. Коррупциягә каршы экспертиза проект теркәлгән көннән алып ун көн эчендә үткәрелә. Кенәгә алып бару өчен җаваплы зат Кенәгәдә теркәлгән көннән алып бер эш көне эчендә Дәүләт комитеты акты проектын экспертиза үткәрү өчен җаваплы затка тапшыра.

3.3.Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре әлеге Тәртипнең 1.4нче пунктына ярашлы рәвештә җаваплы зат төзегән нәтиҗәгә карап ясала һәм Кенәгәдә билгеләнә. Нәтиҗә ясалган көнне үк ул акт проектын җибәргән структур бүлекчәгә тапшырыла.

3.4.Коррупциоген факторлар булганда акт проектын төзегән структур бүлекчә нәтиҗә алган көннән өч көн эчендә проектны эшләп бетерә һәм аны кабат коррупциягә каршы экспертиза ясауга җаваплы затка җибәрә. Кабаттан коррупциягә каршы экспертиза эшләп бетерелгән акт проекты алынган көннән алып өч көн эчендә ясала.

3.5.Эшләп бетерелгән акт проектында коррупциоген факторлар булмаса, җаваплы зат ярашлы нәтиҗәне акт проектын кабат коррупциягә каршы экспертиза ясауга җибәргән структур бүлекчәгә җибәрә.

## 4. Дәүләт комитетының норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыруны тәэмин итү

4.1.Дәүләт комитетының норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру турында мәгълүматны Дәүләт комитетының рәсми сайтының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацион челтәрендә Дәүләт комитеты эшчәнлеген алып баруга хокукый яктан җаваплы затка җибәрү көненә ярашлы эш көне эчендә әлеге проектны әзерләгән Дәүләт комитеты структур бүлекчәсе урнаштыра.

4.2.Дәүләт комитетының норматив хокукый актлар проектларын Дәүләт комитеты рәсми сайтының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацион челтәрендә коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен урнаштыру вакыты җиде эш көненнән ким булмаска тиеш.

4.3. Дәүләт комитетына эксперт нәтиҗәләре җибәрү өчен ясалган электрон почта адресына килгән эксперт нәтиҗәләре Дәүләт комитетында эш производствосын оештыру һәм алып бару белән шөгыльләнүче зат тарафыннан тиешле тәртиптә теркәлә һәм шул ук көнне коррупциоген факторларны карау һәм төзәтү өчен норматив хокукый актларының ярашлы проектларын әзерләгән Дәүләт комитетының структур бүлекчәсенә җибәрелә.

4.4.Дәүләт комитетының норматив хокукый актның ярашлы проектын әзерләгән структур бүлекчәсе:

ике эш көненнән соңга калмыйча эксперт нәтиҗәсендә булган үз позициясен язма рәвештә Дәүләт комитетының хокукый эшчәнлеге өчен җаваплы затка җибәрә;

эксперт нәтиҗәләрен җибәрү өчен ясалган электрон почта адресына эксперт нәтиҗәсе килгән көннән алып унбиш кән эчендә коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыручы Дәүләт комитеты рәисе урынбасары структур бүлекчәсен алып барган бәйсез эксперт имзасы белән мотивацияле җавап әзерли һәм җибәрә (эксперт нәтиҗәсендә ачыкланган коррупциоген факторларны юкка чыгару ысулы турында тәкъдимнәр булмаса). Әзерләнгән җавап Дәүләт комитеты эшчәнлеген хокукый алып баруга җаваплы зат белән килешенә.

4.5 Эксперт нәтиҗәсендә кимчелекләр нигезләнгән һәм тәкъдимнәр исәпләнгән булса, Дәүләт комитетының норматив хокукый актлар проектларын әзерләү өчен җаваплы Дәүләт комитетының структур бүлекчәсе Дәүләт комитетының хокукый эшчәнлеге өчен җаваплы затка Дәүләт комитетының норматив хокукый акты проектын кабаттан бирә. 4.6.Дәүләт комитетының норматив хокукый акты проектын кабат карау кабаттан коррупциягә каршы экспертиза ясауны, шулай ук килгән эксперт нәтиҗәсен карауны һәм аларда булган тәкъдимнәрнең исәп тулылыгын бәяләүне таләп итә.

Татарстан Республикасының сатып алулар буенча Дәүләт комитетында норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру Тәртибенә 1нче кушымта

Коррупциягә каршы экспертизага килгән норматив хокукый актлар һәм норматив хокукый актлар проектларын исәпкә алу Кенәгәсе

| №П/п | Экспертизага акт килү датасы (акт проекты) | Акт исеме (акт проекты) | Проектны эшләүче | Нәтиҗә төзү датасы | Коррупциоген нормаларның булу-булмавы | Нәтиҗәне алды |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Татарстан Республикасының сатып алулар буенча
Дәүләт комитетында норматив хокукый актларга һәм
норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы
экспертиза уздыру Тәртибенә 2нче Кушымта

Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәсе

___________________________________________________________

**(Норматив хокукый акт реквизитлары яисә норматив хокукый акт проектының исеме)**

___________________________________________________________

___________________________________________________________

**(килү датасы)**

___________________________________________________________

**(экспертиза уздыру датасы)**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 декабрендәге «Аерым норматив хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру Тәртибе һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 883нче карары

**(коррупциягә каршы экспертиза уздыруга нигезләмә)**

Актта (акт проектында) коррупциоген норма булу-булмау турында:

___________________________________________________________

Коррупциоген нормалар булган актның (акт проекты) конкрет положениеләре:

___________________________________________________________

___________________________________________________________

Коррупциогенлыкны бетерү формулировкаларын үзгәртү яисә аерым нормаларны юкка чыгару тәкъдимнәре:

___________________________________________________________

___________________________________________________________

___________________________________________________________

Җаваплы зат ____________________ ____________________

(Имза) (Исеме, фамилиясе һәм әтисенең исеме)